СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2022 г. Заинск № 105

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы «Зәй шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 29 октябрендәге 129 номерлы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 декабрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын тикшерү буенча гавами тыңлаулар беркетмәсе һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләр нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясына, Зәй шәһәре Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы «Зәй шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 29 октябрендәге 129 номерлы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы карарына, ТР, Зәй шәһәре, Ленин урамы адресы буенча урнашкан 16:48:060209:2319 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата, үзгәреш кертергә.
2. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATASTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының җир мәсьәләләре, экология һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Р.В. Әгъләмов).

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**